# ЕЛАВЫК ХӘЙРУЛЛА

Көн елагач, төн елагач, өстенә өшкертергә хәзрәткә иттеләр, суфый абзыйдан күз бөтие яздырдылар; Мәхбүбә әбидән имләтеп, аръяк кизләвенә чүпрәк салдырдылар, Хәйрулла туктамады да, туктамады.

Кендек әбисенең чабуыннан кисеп алган чүпрәк белән төсләделәр. Күрше Мәрфуганың толымыннан алган чәчне балавыз белән кушып төзәттеләр, ишек бавын чайкаган суда бисмилла әйтеп коендырдылар, шул судан, салават әйтеп, теленә, иреnенә сөрттеләр. Хәйрулла елаудан өзелмәде.

Көн елады, төн елады: имезгәндә дә елады, тирбәткәндә дә елады, сөйгәндә дә елады, орышканда да елады. Очык булды дип, ак сычканның оясыннан алынган очык ташларын чайкап эчерделәр. Сырт буена дуңгыз кылы чыккандыр дип, Гарифә әбидән аркасын ялаттылар; соңгылыгы арусыз урынга күмелгәндер дип, аны казып алып, каберennән чишмә ага торган Гайниҗамал остазбикәнең янына күмделәр. Хәйрулла басылмады да, басылмады.

Күз кайтару өчен кечкенә кәләпүшенә гөбе тимере, тиен койрыгы, үрән калагы тектеләр. Шайтан качырыр өчен бисмилла язылган көмеш зөлфекар, артыш шакмагы астылар. Аның елавы өзелмәде, чинавы кимемәде.

Им иттерү өчен кырык чакрымнан бер чуаш карчыгын алып килделәр. Мунча ташлары, каз канатлары, икмәк катылары белән им иттеләр. Бабайлардан калган келәү тоткандыр дип, ап-пак каз суеп, каз шулпасы, борай боткасы ашаттылар. Кырыгынчы көнне озын койрыклы, кәкре мөгезле сарыкны гәкыйка корбанга* чалдылар, корбанның буыннарын, кабыргаларын, калак сөякләрен — барысын җыеп, ага торган суга ташладылар.

Хәйрулла елавын киметмәде. Йокысы килсә дә елады, йокысы туйса да елады; шикәрле сөт белән туйдырылса да елады. Әнисе аның елавына күнде. Аның «балам» дип һәр кычкыруы сыкрата торган йөрәгенең нечкә тамыры тупасланды, тутыкты. Әтисенең дә күңеле тынычланды, куркусы качты. Елавына беркемнең дә исе китмәгәнне сизенгән кебек, иртәдән кичкә кадәр чинавының кыйммәте кимегәнен белгән кебек, Хәйрулла тавышына да иренү

кушылды. Ул сүрәнләндереп карлыккан тавышы белән яшьсез генә еларга кереште.

Елавы үсүенә зарар итмәгәнгә, ул елады да үсте. Үсүе елавының көчен киметмәгәнгә, ул үсте дә елады.

— Энем, энем Хәйрулла, канатым, энем, энем! — дип, апасының кечкенә бармагын бәбәсенең йомшак бит алмасына тиереп уйнавына да ул кечкенә иреннәрен матур итеп көләргә тотынгач та, иң зур вазыйфасын онытуын хәтерләгән кебек, авызын җәеп, тешсез теш итләрен ыржайтып еларга тотынганга, аның көлүе дә матурлыгын, гөнаһсызлыгын югалтты.

Тозлы күз яше аның балалык тавышын тутыктырганмы, теле ачылып, «әни» дип дәшкән беренче сүзе чинаган кебек, эчтән елаган кебек чыкты. Хәйрулла бөтен сүзен буяп чыгарганга, аның бөтен сүзе, бөтен тавышы буйдан ыңгырашуга әверелде.

Елаган кебек көлүе, мескенләнеп, ыңгырашып сөйләве аның исеменә «Елавык»* кушаматы такты. Таза, нык, кара башлы өч яшендәге Хәйрулла урам буйлап йөгереп йөри башлагач та, аның кушаматы артыннан калмады. Күрше малайлары, кызлары алдында «Елавык» дигән сүз мәңгелеккә төшмәскә килеп ябышты.

## Искәртмәләр һәм аңлатмалар:

*Гәкыйка корбан* — бала тугач, җиденче, тугызынчы, йә кырыгынчы көнне чалына торган корбан. ( Г.Исхакый искәрмәсе.)

*Зөлфекар* — кылыч

*«Елавык»* — күп елаган кешегә елак диләр;тагын күбрәк елаган (бертуктаусыз елап кына торган) кешегә елавык диләр, имеш. (Г.Исхакый искәрмәсе.)

**Елавык Хәйрулла** — Хикәя беренче тапкыр «Ак юл» журналының 1913 ел 9 санында басылган. Икенче тапкыр Казанда «Мәгариф» нәшрияты, «Өмет» типографиясендә «Балалар күңеле» сериясендә төрле авторларның

әсәрләре тупланган җыентыкта 1921 елда басылып чыга. 2 нче төп, 7 нче китап. Ике басмада да «өзек» дип куелган. Әдипнең шушы өзекне эченә алган әдәби әсәре әлегә билгеле түгел.

*Очык* — сидек тота алмау авыруы.

*Үрән калагы* — бака, кашыгыннан зуррак, түгәрәк формадагы кабырчык; ракушка.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 2 том. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1999. Б.417-418.